ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
«Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Еленовский торак
пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**27.11.2024** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 27 ноябрендә 08 сәг 00 мин уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гранданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Еленовский торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле) һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларын (ата-аналар, хатын, балигъ булган балалар) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдаланурга ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Еленовский поселокның Красная ур. юлларны вак таш сатып алу һәм салу һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

2. Торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чаптыру, юлларны кардан чистарту һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 11 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 7 кеше, бу 63,6 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 7 катнашучысы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Еленовский торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Еленовский торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле) һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларын (ата-аналар, хатын, балигъ булган балалар) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Еленовский поселокның Красная ур. юлларны вак таш сатып алу һәм салу һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы Р.Р. Мауликаев